ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан карап бетерелмәгән закон проектлары буенча җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының җаваплы комитетларын билгеләү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетын әлеге карарга кушып бирелгән 1 нче исемлек нигезендә закон проекты белән эшләгәндә җаваплы итеп билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитетын әлеге карарга кушып бирелгән 2 нче исемлек нигезендә закон проектлары белән эшләгәндә җаваплы итеп билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетын әлеге карарга кушып бирелгән 3 нче исемлек нигезендә закон проекты белән эшләгәндә җаваплы итеп билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитетын әлеге карарга кушып бирелгән 4 нче исемлек нигезендә закон проектлары белән эшләгәндә җаваплы итеп билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитетын әлеге карарга кушып бирелгән 5 нче исемлек нигезендә закон проектлары белән эшләгәндә җаваплы итеп билгеләргә.

6. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетын әлеге карарга кушып бирелгән 6 нчы исемлек нигезендә закон проектлары белән эшләгәндә җаваплы итеп билгеләргә.

7. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитетын әлеге карарга кушып бирелгән 7 нче исемлек нигезендә закон проектлары белән эшләгәндә җаваплы итеп билгеләргә.

8. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетын әлеге карарга кушып бирелгән 8 нче исемлек нигезендә закон проектлары белән эшләгәндә җаваплы итеп билгеләргә.

9. Әлеге карарның 1 – 8 пунктларында күрсәтелгән исемлекләргә кертелмәгән Татарстан Республикасы законнары проектларын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравыннан төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 20 сентябре
№ 35-VII ДС

1 нче исемлек

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советының**
**Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты**

| № т/б | Проект исеме | Каралу стадиясе |
|---|---|---|
| | Татарстан Республикасы законы проекты | |
| | | |
| 1. | «Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 587-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты | Алдан карауда тора |

2 нче исемлек

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советының**
**Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты**

| № т/б | Проект исеме | Каралу стадиясе |
|---|---|---|
| | Татарстан Республикасы законнары проектлары | |
| 1. | «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 588-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты | Алдан карауда тора |
| 2. | «Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 2 өлешенең үз көчен югалтуын тану хакында» 591-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты | Алдан карауда тора |
| 3. | «Салым түләүченең күчемсез мөлкәт объектын сатудан керемен билгеләү өчен кулланыла торган киметүче коэффициент күләмен билгеләү турында» 592-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты | Алдан карауда тора |
| 4. | «2025 елга Татарстан Республикасында хезмәт базарының төбәк үзенчәлекләрен чагылдыра торган коэффициентны билгеләү турында» 594-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты | Алдан карауда тора |
| 5. | «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына һәм «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 595-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты | Алдан карауда тора |

3 нче исемлек

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советының**
**Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты**

| № т/б | Проект исеме | Каралу стадиясе |
|---|---|---|
| | Татарстан Республикасы законы проекты | |
| 1. | «Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 593-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты | Алдан карауда тора |

4 нче исемлек

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советының**
**Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты**

| № т/б | Проект исеме | Каралу стадиясе |
|---|---|---|
| | Татарстан Республикасы законнары проектлары | |
| 1. | «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 11 һәм 13 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 596-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты | Алдан карауда тора |
| 2. | «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» 598-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты | Алдан карауда тора |

5 нче исемлек

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советының**
**Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты**

| № т/б | Проект исеме | Каралу стадиясе |
|---|---|---|
| | Татарстан Республикасы законы проекты | |
| 1. | «Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 597-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты | Алдан карауда тора |
| | Федераль законнар проектлары | |
| 1. | «Россия Федерациясендә умартачылык турында» Федераль законның 13 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 101ПЗ номерлы федераль закон проекты | Алдан карауда тора |
| 2. | «Атмосфера һавасын саклау турында» Федераль законның 19 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 71ПЗ номерлы федераль закон проекты | Алдан карауда тора |

6 нчы исемлек

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советының**
**Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты**

| № т/б | Проект исеме | Каралу стадиясе |
|---|---|---|
| Федераль законнар проектлары | | |
| 1. | «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 1.8 һәм 4.5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 45ПЗ номерлы федераль закон проекты | Алдан карауда тора |
| 2. | «Хәрби хезмәткәрләрнең, хәрби җыеннарга чакырылган гражданнарның, Россия Федерациясе эчке эшләр органнары, Дәүләт янгынга каршы хезмәте рядовой һәм җитәкче составы затларының, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнары хезмәткәрләренең, Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләре хезмәткәрләренең, Россия Федерациясе мәҗбүри үтәтү органнары хезмәткәрләренең гомерен һәм сәламәтлеген дәүләт мәҗбүри иминләштерүе турында» Федераль законның 2 статьясына һәм «Хәрби хезмәткәрләрнең акчалата тәэмин ителеше һәм аларга аерым төр түләүләр бирү турында» Федераль законның 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 69ПЗ номерлы федераль закон проекты | Алдан карауда тора |

7 нче исемлек

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советының**
**Социаль сәясәт комитеты**

| № т/б | Проект исеме | Каралу стадиясе |
|---|---|---|
| | Татарстан Республикасы законы проекты | |
| 1. | «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 6 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 448-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты | Алдан карауда тора |
| | Федераль закон проекты | |
| 1. | «Иминият пенсияләре турында» Федераль законга үзгәреш кертү хакында» 58ПЗ номерлы федераль закон проекты | Алдан карауда тора |

8 нче исемлек

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советының**
**Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты**

| № т/б | Проект исеме | Каралу стадиясе |
|---|---|---|
| | Татарстан Республикасы законнары проектлары | |
| 1. | «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыра торган муниципаль мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 589-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты | Алдан карауда тора |
| 2. | «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 590-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты | Алдан карауда тора |